Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык  авыл җирлеге
Мамык авылы торак пунктында гражданнар җыены
КАРАРЫ

«28» ноябрь  2022 ел  № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Мамык  авыл җирлеге Мамык авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидларыннан,  Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, яшәү урыны буенча теркәлгән, әмма яшәмәгән гражданнарнардан тыш, 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган  акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

-  Торак пункт чикләрендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

- Урам утлары януын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;

-3 янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру;

- Мамык авылында җәяүлеләр күперен ремонтлау (бизәлешне алыштыру, буяу, материал сатып алу.

Халык җыенында рәислек итүче:  В.В. Рыжков

Мамык авыл җирлеге башлыгы  В.В. Рыжков